**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Урсай авыл җирлеге Советы карары**

Урсай ав. №116 "18 " октябрь 2018 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 14.05.2018 №100 карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясындагы 2 өлеше нигезендә

Урсай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 14.05.2018 №100 карарына үзгәреш кертергә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«4. Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Абдуллин